Бөтендөнья балалары, дуслашыгыз!



САБАНТУЙ

2 август, 1995 ел.
№ 59
(4671)

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ГАЗЕТАСЫ







Әлбәттә, әтиләре, абыйлары белән беррәттән иртән торып эшкә киткәндә, өлкәннәр янында басуларда уңыш җыйганда үсәләр алар. Икмәк табынга килгәч кенә түгел, басуларда чакта ук үстерә малайларны, олы кеше итә.

Әнә комбайнында басып торган Ямаширмә егете Илнур Гатиятовның да карашы нинди җитди. Рамил Исмәгыйлев белән Рамил Габдрахманов та фотообъективка балалыкларын онытып, ирләрчә карап торалар. Ә иген өстендәге дүрт егет елмая. Кояшлы матур көнгә, үзләренең менә дигән ярдәмчеләр була алуларына сөенәләр дә бугай.

Әйе, авыл малайларын басулар үстерә, үзләре җыйган игеннәр егет итә.

М. ШАКИРҖАНОВ
фоторәсемнәре.
Биектау районы.



КҮҢЕЛЛЕ ЯШИБЕЗ

ҮТКӘН уку елының иң соңгы сборында безнең дружина еллык эшләргә йомгак ясады. Баксаң, шактый эшләр эшләгәнбез икән, ләбаса. Көз көне колхозга бәрәңге алуда булыштык, ял көне урман полосаларын чистарттык, «Кырмыска» операциясендә актив катнаштык. Былтыр гына безнең сафка баскан яшь эзтабарларыбыз да тырышты. Алар көзен, язын сәяхәт, экскурсияләргә йөрделәр, андагы чишмәләрне чистарттылар.

Мәктәбебез белән ярдәмчесез калган карт-карчыкларны шефка алдык. Аларны кыш буе чишмә суы белән тәэмин итеп тордык.

Уңыш бәйрәме, театр атналыгы, яңа ел бәйрәме, «Ягез әле, егетләр», «Ягез әле, кызлар», Җиңүнең 50 еллыгына багышланган альбом-эстафета тапшыру, обелиск янындагы митинг кебек вакыйгаларны бик күңелле итеп уздырдык.

Әйе, күп эшләр эшләгәнбез бу узган уку елында. Моның өчен без тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Рәйсә апа Рәфыйковага рәхмәтле. Яңа уку елын да шулай истә калырлык итеп уздырасы иде.

Эльвира МИФТАХОВА.
Кама Тамагы,
Олы Карамалы.



МИНЕМ ЭНЕМ

МИҢА ӘНИЕМ кечкенә вакытта энем белән булган хәлләр турында сөйләде.

Бервакыт әнием керләр юарга чыккан, ә мине энем белән калдырган. Энем бик каты еларга тотынган, ә мин, ни эшләргә белмәгәнлектән, үзем аңардан да катырак елый башлаганмын. Энем диваннан егылып төшеп барганда гына, әнием килеп кереп, аны тотып алган.

Кайчакларда энем үземне кыерсыта да, ләкин мин аны барыбер яратам.

Менә шундый ул минем энем!

Лилиана ХАРИТОНОВА.
Апас, Иске Тәрбит.

ДУСТЫМ

МИНЕМ якын дустым бар. Ул Әнвәр исемле. Без аның белән бер подъездда торабыз. Тырыш та һәм акыллы да Әнвәр. Без гел бергә уйныйбыз. Бигрәк тә аның белән шашка уйнарга яратабыз. Мин җиңеләргә яратмыйм. Беренче урынга чыгу үзе күңелле.

Марат САЛЬМУШЕВ.
Казан, 13 нче гимназия.

ТЫЛСЫМЛЫ ТАЯГЫМ БУЛСА

Безнең йортта өч кыз. Өчебез дә китап укырга, рәсем ясарга, чигәргә, бәйләргә яратабыз. Гомумән, эшкә әни белән әбидән өйрәнәбез. Әбиебез безнең бик оста чигүче булган. Ул чиккән чәчәкләр күзнең явын алырлык матур һәм нәфисләр.

Буш вакытларда без кычкырып әкият укырга яратабыз. «Мең дә бер кичә», татар, рус һәм тагын бик күп халык әкиятләре... Ул андагы батырлар, ул андагы дию пәриләре, ул тапкыр егетләр, сөйләшә белүче җәнлекләр, ялганчы патшалар, күз камаштырырлык матурлыкка ия булган кызлар... Ә миңа бигрәк тә... әнә шул тылсымлы таягы булган Фея ошый. Шәп бит, таякны бер селтәдең... менә сиңа алтын карета, икенче селтәдең... Их, менә шул тылсымлы таяк минем кулда булса иде!



Ә шулай да бер көнне тылсымлы таяк минем кулга төште. Аны миңа әкияттәге Фея бирде. И, Ләйлә белән Чулпан сеңелләрем кызыкты да инде ул таякка. Ә мин, алар тынычлансын дип, икесен дә бик матур принцессага әйләндердем. Болай да матур сеңелләрем курчак кебек булдылар. «Ә хәзер,— дидем мин,— без «Гүзәллек иле»нә сәяхәт итәбез». Сеңелләрем чыр-чу килеп әзерләнгән арада мин таягымны бер селтәдем. Менә ул «Гүзәллек иле». Кара әле, урамда бар халык матур итеп киенгән, берберсе белән бик итагатьле итеп кенә сөйләшәләр. Безгә бик кызык, бөтен нәрсә ят, искиткеч матур һәм яңа. Ул йортлар: берсе ике катлы, икенчесе өчлы, өченчесе гөмбәзле, дүртенчесе тагын әллә нинди кыландырып салынган. Аларны монда коттеджлар дип атыйлар икән.



Ләйләне ясле кызыксындырды, ул шунда китте. Чулпанны мәктәп сокландырды, ул анда юл алды.

Ә мине бу илнең яшьләре кызыксындыра. Менә клуб алды. Таза, яшь, чибәр егетләр тора. Ләкин ни гаҗәп — берсе дә тәмәке пыскытмый, исерекләр дә күренми. Мине күргәч матур итеп сәлам бирделәр. «Клубка кер, чибәр кыз, хәзер дискотека башлана»,— диделәр. Аптырадым тәмам. Клуб эченә керсәм, нинди гүзәллек! Теттереп татарча биилар бит. Бер генә кеше дә тик тормый. Кыскасы, «Гүзәллек иле»ннән бик нык гаҗәпләнеп кайттык без һәм әле дә булса шул илне сагынып искә алабыз.

Энҗе ЯКУПОВА.
Балтач, Түнтәр.

✦✦✦ БЕЗНЕҢ ЯРАТКАН ӘДИПЛӘРЕБЕЗ

Әхсән Баянов

ИҖАТЫ ТУРЫНДА

● Әхсән Баянга туктаусыз эзләнү хас. Шул күзлектән караганда, «Һәйкәл» драматик поэмасы — язучының иҗатында ирешкән иң зур уңышларның берсе. Автор киң колачлы бу әсәрендә художник буларак та, шулай ук гуманист буларак та, ныклап ачылып җитә.

Сибгат ХӘКИМ, 1971.

● Шагыйрьлеген мин аның бик тиз таныдым. Әйбәт шагыйрь, фикерләүче шагыйрь — дәрәҗәләрен төрле бүләкләр һәм исемнәр белән ныгыткан башка шагыйрьләрдән һич тә ким түгел.

Әмирхан ЕНИКИ. 1992.

● Ә. Баяновның шигъри автобиографиясе («Сез аңларсыз мине») — кызыклы һәм тәэсирле, бөтенләе белән моң һәм өмет, дәүләтнең «көчле кешеләрен» гаепләү һәм хезмәт кешеләренең түземле рәвештә гафу итә килүләре, гаделсезлеккә ачу тойгысы һәм көчсезләргә мәхәббәт ноталары белән яңгырашлы ителгән.

Аделина АДАЛИС,
рус шагыйрәсе. 1965.

● Җыентыкка исем биргән поэма («Сез аңларсыз мине») аерылып тора. Анда ачыктан-ачык, туп-туры, сызланулы рәвештә идеаллар һәлакәте, туган авылның авыр тормышы, гаделсезлек һәм алдау бәян ителә.

Николай СИДОРЕНКО, 1965.

● Әхсән Баянов — безнең хәзерге әдәбиятыбызда күренекле урын алган, елданелга иҗади колачын киң җәя башлаган язучыларыбызның берсе... Аның үзенчәлекле таланты кайсы тармакта, кайсы жанрда тулырак ачыла соң? Моңа хәзергә әле беркем дә анык җавап бирмәстер, чөнки заман рухы белән яшәүче, кыю эзләнүчән бу әдипнең үсү процессы шактый катлаулы, бер генә яссылыкта түгел.

Хәсән ХӘЙРИ. 1979.

● Шагыйрь поэзияне замандашларыбызның эчкерсез кичерешләрендә, ялгансыз, ихлас хисләрендә күрә. Ул поэзиягә матур бизәкләр яисә купшы тел чаялыгы белән түгел, ә бүгенге тормыш картиналарын сурәтләү белән ирешә.

Хисам КАМАЛОВ. 1971.

● Безнең талантлы шагыйрьләребез бар, талантлы прозаикларыбыз бар, әмма бүгенге язучылардан шигырен дә, прозасын да, драмасын да Әхсән Баяновтай өчесен бергә, бердәй талант белән язганнары — бармак төртеп санарлык кына.

Хәсән САРЬЯН. 1977.

● «Ут һәм су» дилогиясенең әдәбиятта лаеклы урын алачагына ышанам.

Гариф АХУНОВ. 1983 ел.

● Ә. Баянов прозага шигырьдән килде, проза өлкәсенә шагыйрьлеген дә алып килде. Ул безнең әдәбиятта эчке монологка корылган лирик прозаны үстерү эшенә күп өлеш кертте.

Фәрваз МИҢНУЛЛИН. 1983.

● Әхсән Баянов табигате белән полемист... Нинди бәхәс growth ирониясез, сарказмсыз булсын инде. Артык туры һәм күзгә бәрелүчән булмаса да, бу сыйфат татар шагыйренә (Ә. Баяновка) хас. Тәрҗемәче Леонович шуны тоя алган!

Рафаэль МОСТАФИН. 1984.


● «Җәй белән җәй арасы» повестеның төп герое — Ильяс характер буларак ифрат та күпкырлы, катлаулы, хәтта каршылыклы. Әмма ул үсештә бирелүе, психологик һәм социаль анализның төгәллеге белән ота, аклана. Бу характерны мин автор уңышы, табышы дип кенә әйтмәс идем. Әдәбиятыбызда телгә керерлек образ булачак ул.

Мәхмүт ХӘСӘНОВ. 1990 ел.

● Шигырьләрендә ул мәхәббәт рухын, аның күпьяклы чагылышларын тулырак сынландыру юнәлешендә Дәрдемәнд белән Туфан, рус поэзиясеннән А. Ахматова белән Б. Пастернак эзләнүләренә якыная.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. 1991.

● Әхсән Баяновның һәр әсәре. фәндәге яңа ачышлар кебек, укучыга тормышның



ТОРМЫШ ЮЛЫ

Әхсән Фәтхелбаян улы БАЯНОВ 1927 елның 8 декабрендә Башкортстан республикасының Илеш районы Әшмән авылында туган. 1943 елда күрше Ишкар авылында җидееллык мәктәпне тәмамлагач, берничә ел колхозда эшли. Аннары 1947-1950 елларда район үзәге Югары Яркәйдәге Культура йортында художество җитәкчесе хезмәтендә була. Шунда, төп эшеннән аерылмыйча, урта мәктәпне тәмамлый. Бер ел шул ук районның Карабаш авылында укытучылык иткәннән соң, 1951 елда Казанга килә һәм В. И. Ульянов-Ленин исемендәге университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. 1956 елда университетны тәмамлаганнан бирле озак еллар журналистика өлкәсендә эшли. 1956-1962 елларда «Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә башта хәбәрче, соңыннан әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире, 1962-1966 елларда «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре, 1977-1981 елларда исә шул ук журналның баш редакторы урынбасары вазифаларын башкара.

Әхсән Баянов әдәбият сөючеләргә иң әүвәл шигъри әсәрләре белән таныла. Беренче шигырьләре район газетасында 1944 елда ук, ә республика матбугатында 1951 елдан күренә башлый. 1959 елда исә «Диңгез шавы» исемле беренче җыентыгы басылып чыга. Хәзерге көндә ул шигъри әсәрләре тупланган дистәләрчә китап авторы. Шагыйрьнең күп санлы лирик һәм фәлсәфи-публицистик шигырьләре, балладалары, «Яшел мәйдан» (1957), «Диңгез шавы» (1958), «Мират» (1959), «Сез аңларсыз мине» (1963), «Сәяхәтнамә» (1961), «Һәйкәл» (1970), «Кышкы чәчәкләр» (1974) кебек поэмалары заманның характерлы билгеләрен, үз буынының уй-хисләрен, яшәү һәм хезмәт проблемаларын сәнгатьчә гәүдәләндерү юлында үзенчәлекле иҗат тәҗрибәсе буларак, бүгенге татар поэзиясе хәзинәсендә лаеклы урын алып торалар. Ә «Алтын кашбау» (1980-1986) һәм «Кара кош» (1989-1991) исемле шигъри трагедияләрендә, тарихи вакыйгаларга кереп, халкыбыз язмышына кагылышлы тирән иҗтимагый һәм фәлсәфи фикерләрен тагын да үстереп, шагыйрь гыйбрәтле һәм шул ук вакытта романтик картиналар сурәтләде.

Ә. Баянов проза һәм драматургия жанрларында да нәтиҗәле эшли. Нигездә сугыш алды һәм сугыштан соңгы авыл тормышы вакыйгаларына бәйләп, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне чагылдырган «Яшьлегемне эзлим» (1966), «Дүрт монолог» (1968), «Тау ягы повесте» (1972), «Төлке тоту кыен түгел» (1975), «Тавыш — табигать бүләге» (1977), «Аязучан болытлы һава» (1978), «Аргы яр» (1979) повестьлары һәм Кама буендагы төзелеш картиналарын гыйбрәтле язмышлар аша гәүдәләндергән «Ут һәм су» (1971), «Таш китап» (1981) романнары укучылар һәм әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята.

Әхсән Баянов — «Күзләре нинди иде», «Һәйкәл» һәм «Зәңгәр кыңгыраулар» исемле драмалар авторы.

Ә. Баяновның шигырьләре рус телендә «Дружба народов», «Москва», «Крестьянка» кебек үзәк матбугат органнарында, «Яшьлегемне эзлим» повесте — «Волга», ә «Дүрт монолог» повесте «Огонек» журналларында басылып чыкты.

Ә. Баянов әдәби иҗат эшен җәмәгать эшләре белән тыгыз бәйләп алып бара. Озак еллар буе ул «Казан утлары» журналы һәм «Идел» альманахы редколлегияләрендә әгъза булып торды. Ул — 1974 елдан бирле Татарстан язучылар союзы идарәсе әгъзасы. 1989 елдан башлап Татарстан язучыларының әдәби фонд идарәсе рәисе булып эшли.

Әдәбиятны үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әхсән Баянов 1977 елда «Почет билгесе» ордены белән бүләкләнде. 1988 елда драматургиядәге уңышлары өчен аңа Татарстан республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Ул «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» һәм «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 50 ел» медальләренә лаек булды.

ТҮТЕКӘЙ

ҖӨҮДӘТ СҮЗЕ

БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

● Шигырьләрендә ул мәхәббәт рухын, аның күпьяклы чагылышларын тулырак сынландыру юнәлешендә Дәрдмәнд белән Туфан, рус поэзиясеннән А. Ахматова белән Б. Пастернак эзләнүләренә якыная.

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. 1991.

● Әхсән Баяновның һәр әсәре, фәндәге яңа ачышлар кебек, укучыга тормышның моңа кадәр мәгълүм булмаган яңа якларын күрсәтеп бирә.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. 1994.

● Әхсән Баянның тыгыз тәнле шигырьләрендә... чынбарлык, тәҗрибәле шагыйрь каләменнән тәгәл гыйбарәләр, фәлсәфи тирәнлек, мәгънәле фикерләр теркәлгән.

Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. 1994.

Әнисе Рәхимә Китапова. 1958.

Алты яшьлек улы — фехтование буенча яшьләр арасында булачак дөнья чемпионы, халыкара спорт мастеры Эльбрус белән. 1964.

Тәрҗемәче Владимир Николаевич Леонович белән Кырлайда, Тукай янында.

ТҮТЕКӘЙ

Мин бирдем кыш буе көнбагыш,
Көнбагыш беткәндә — эпикәй.
Ярады һәм ярма — яраттың,
Мин сине яраттым, песнәккәй.

Яз килеп яшәргәч табигать,
Оныттың бугай тик, песнәккәй.
Абзыкай, абзыкай, димәдең.
Сайрадың:
— Түтекәй, түтекәй!

Апамны зурлагач, мин риза,
Сайрый бир, сайрый бир, песнәккәй.
Яратып тыңлыйбыз без икәү:
— Түтекәй, түтекәй, түтекәй.

ҖӘҮДӘТ СҮЗЕ

Укытучы апа сорый,

Ә без бирәбез җавап

— Үскәч кем буласың килә?

— Агроном.

— Врач.

— Солдат.

Әйтә сүзен Җәүдәт тә:

— Пенсионер, әлбәттә.

КОШЛАР РӘХМӘТЕ

КҮРШЕ абыйның күз алдында төлке наян кыр үрдәген йомыркасы өстеннән йолкып алган да коткарырга ташланып өлгергәнче качкан. Ояда үрдәк йомыркалары калган. Өйгә кайткач аларны утырган тавык астына салдылар. Тиздән үрдәк бәбкәләре борын төртеп чыкты. Бәбкәләрне тавык җәй буе ияртеп йөри, дөнья белән таныштыра, куркыныч яныса саклый, ягъмур яуса чебиләрен сыйган кадәр үз канаты астына җыя, афәттән саклый. Җаны гына өлешен бирми үзләренә. Бәлки әле җанын да бирер иде.

Кошлар үсә шулай, үзә җәй. Тик көз җиткәч, гаҗәп хәл: кара тавыкның бибиләре, җирне ташлап, һавага күтәрелә дә җиләнешме-җиләнәләр. Тавык мескен очынып сикергәләсә дә, бәбкәләр артыннан күтәрелергә теләп җилпенсә, талпынса да, табигать аңа очар канат бирмәгән шул. Кара тавыкның ул кыткылдау, үрсәләнүләреннән: «Кара, карагыз, әрәм үтте җәем, юкка чыкты чебиләрем!» — дигән үкенеч авазы ишетелә.

Ә күрше абый үзе һәм күршеләре үрдәкләр һич тә алай үрсәләнмиләр. Үрдәкләр ана тавыкка да, хуҗага да рәхмәт йөзеннән өй тирәли берничә кат очып әйләнеп, тыйнаграк кына булса да, шулай сәлам биреп китәләр. Җәйнең, изгелекнең әрәмгә чыкмавын шул рәвешле бик әйбәт сиздерергә тырыша алар.

ҖЫР ДӘВАМ ИТӘ

КҮКТӘ тургай үзенең мәңгелек көйләрен, игенче күңеленнән алган өметләрен, сөенечләрен җиргә сибә. Сабанчыларга яңарган дәрт өсти, аның көмеш кыңгырау булып чыңлавы — яңа уңышлар, шатлыклар вәгъдә итә. Кешеләр аның якты теләкләренә сокланса, тик бу вакытта якын-тирәдә генә карчыга рәвешендәге усаллык та булган икән. Һәм аны тургай бөтенләй бүтән сәбәп белән кызыктырган.

Карчыганың үлеп ашыйсы килә иде. Шул сәбәпле, кызыгуга чыдый алмыйча, карчыга җайлы мизгелен көтте. Һәм тургай өстенә канатлы җырга таба җәядән очкан ук тизлеге белән атылды. Кинәт сабан җыры өзелде, тынды. Ләкин әле кош исән иде. Тургай да таш шикелле җиргә төшә башлады. Аның артыннан — карчыга... Вакытны кайсы тизрәк узар?

Шундый да кыска мизгелдә тургай дөрес чара сайлап өлгерә — сабанчы янына килеп егыла ул...

Карчыга атлы ерткыч исә игенчедән курка, тиз үк кача.
Тургай исән кала.
Җыр дәвам итә.

билгесе» ордены белән бүләкләнде. 1988 елда драматургиядәге уңышлары өчен аңа Татарстан республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Ул «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында фидакарь хезмәт өчен» һәм «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 50 ел» медальләренә лаек булды.

БАСЫЛЫП ЧЫККАН КИТАПЛАРЫ

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНДА:

Диңгез шавы. 1959.
Еллар тавышын тыңлыйм. 1962.
Мират. 1963.
Әйт сүзеңне, яшьлек! 1965.
Мәңге зәңгәр күгебез. 1966.
Яшен исе. 1967.
Ике аккош. 1968.
Елларга ышаныгыз! 1969.
Сез аңларсыз мине. 1971.
Ут һәм су. 1973.
Язмыштан узмыш. 1975.
Җәй — яшел кош. 1976.
Елларга сәяхәт. 1977.
Тау ягы повесте. 1979.
Аязучан болытлы һава. 1981.
Ак канатлар. 1983.
Таш китап. 1984.
Заман сурәтләре. 1985.
Җыр дәвам итә. 1986.
Язмыштан узмыш. 1987.
Алтын кашбау. 1989.
Аргы яр. 1990.
Сайланма әсәрләр. 1 нче том. 1993.
Сайланма әсәрләр. 2 нче том. 1993.

РУС ТЕЛЕНДӘ

Вы поймете меня. Москва. Советский писатель. 1968.
Ищу молодость. Сов. писатель. 1971.
Зимние цветы. Современник. 1975.
Повесть горной стороны. Современник. 1978.
Судьба стучится в дверь. Таткнигоиздат. 1980.
Другой земли нет. Сов. писатель. 1983.

«Казан утлары» редакциясендә авторлар һәм редколлегия әгъзалары белән. Утырганнар (сулдан) — Әхсән Баянов, Гомәр Бәширов, Зәки Нури, Афзал Шамов, Мирсәй Әмир, Риза Ишморат. Басып торалар — Шамил Бикчурин, Рафаэль Мостафин. 1974.

Оныгы Сәрвиназ белән. 1994.

«Яшь ленинчы» редакциясендә кунакта. Сулдан уңга — Әхсән Баянов, Рөстәм Мингалим, Ренат Харис. 1973.

«Социалистик Татарстан» газетасы редакциясендә авторлар белән. Алгы планда (сулдан) — шагыйрь Зыя Мансур, композитор Исмай Шәмсетдинов, арткы планда — Әхсән Баянов, артист Фатих Шәрәфиев, редактор Гадел Рәбков. 1958.

Артист Айрат Арсланов белән. 1987.

Каләмдәшләре арасында. Уңнан сулга: Н. Гыйматдинова, Г. Ахунов, Ә. Баянов, Р. Вахитов. 1984.

Укучылар белән очрашуда. Уңнан сулга: Т. Миңнуллин, Ш. Галиев, Ә. Баянов, И. Юзеев. 1985.



АВЫЛДА туып-үскән бик күпләрнең, бигрәк тә ир затларының атларны яратуы гаҗәп түгел. Чөнки дөньяны атсыз күз алдына китерүе бик кыен. Мин дә авыл баласы. Шуңа күрә, ярты гасыр гомерем шәһәрдә узса да, балачагымны искә төшергәндә (ә бу бик еш була), атларны һич тә онытмыйм. Чөнки ат бик тә күңелгә ятышлы, акыллы җан иясе, хәтта аны хайван дип атыйсы килми... Атларны газаплый торган малайлар турында матбугаттан укып шаклар катам. Минемчә, нормаль акыллы кеше бервакытта да атны җәберләмәс.

Ат белән эт — кешенең кулга ияләштергән иң беренче юлдашлары, ярдәмчеләре. Ат белән җир сөреп, иген чәчеп халык ач үлемнән котылган. Кыргый җәнлек аулап кына көн итеп булмавын күптән белгәннәр. Шул тыныч тыңлаучан җан иясен сугышларга тыгу гаделсезлек булган, әлбәттә. Әмма бу үзе башка, махсус сөйләшүне таләп итә торган мәсьәлә... Ә бу очракта мин авылыбызның даны булган Турат турында берничә сүз әйтмәкче булам. Ел саен район үзәгендә, Йөрүзән елгасы буенда Олы сабантуй була. Табигый, бу бәйрәмнең иң дулкынландыргыч мизгеле булып ат ярышы тора. Безнең якның күпчелеге башкорт авылларыннан торгач, моңа әһәмият бирү тагын да арта. Чөнки, кем әйтмешли, башкорт ат өстендә туа, ат өстендә җан бирә. Башкортлар ярышка үзләренең иң яхшы атларын чыгаралар. Шулай да биш ел рәттән беренчелекне безнең (димәк, татарларның) Тураты алып килде. Ул бөтен авылыбызның горурлыгына әйләнде. Турат исеме телләрдән төшмәде. Без, малайлар, аңа такмак та чыгардык:

Турат ул бер генә, алтын ялы бөдрә,
Шундый гүзәл җан иясен сөймәс икән кем генә...

Әмма табигатьнең үз кануннары бар: Турат олыгая башлады һәм соңгы ярышта икенче урынга калды. Ике-өч адымга гына. Турат җиңелүне күтәрә алмады, ахрысы, гөрс итеп җиргә үзен ыргытты да шундук җан бирде. Әйтерсең лә, борынгы рим гладиаторы. Шуның белән сабан туеның яме китте, халык тиз генә тарала башлады. Ә бу хәл безгә яшен суккандай тәэсир итте...

Безнең авылда беренче йөк автомашинасы 1937 нче елда пәйда булды. Аны әткәй (колхоз рәисе) белән шофер Рәхмәтулла абзый Уфадан сатып алып кайттылар. Бу үзенә күрә республикадагы иң алдынгы колхозларның берсенә бүләк бирү сыман саналган. Ул чакта тракторлар да юк дәрәҗәсендә иде. Шуңа күрә бихисап авыл эше атлар җилкәсенә төште. Бездән 35 километрда булган Мөрсәлим станциясенә — элеваторга — дәүләт амбарына ашлык ташу үзе генә ни тора иде! Әмма атлар өчен иң авыр вакыт сугыш еллары булды. Мин боларның һәммәсен үз күзем белән күрдем, тәнем-җаным белән тойдым. Чөнки нәкъ шул чакта, укуымны өзмәгән килеш, ике ел бригадир ярдәмчесе, ике ел комбайнчы булып эшләдем. Кешеләргә искиткеч кыен булса да, атларга икеләтә авыр иде. Кеше ул кеше инде, авырса яки йөрерлек хәле калмаса, эшкә чыкмаска мөмкин. Ә атның теле юк, күзләрендә әйтеп-сөйләп бетермәслек моңсулык кына була... Мескенкәйләр солы дигәнне күрмәделәр. Печән дә җитмәде. Бөтен нәрсә — фронт атларына — кавалериягә китеп барды. Ә коры салам белән генә кая барсын. Җәен яшь үлән утлавын утладылар. Ләкин ял итми көн дә җигелә торган атларга моның файдасы аз булды. Өстәвенә, арык атларны корчаңгы авыруы эләктереп алды. Ветсанитарлар аларны үзләренчә дәвалап карадылар. Әмма хәлсезләнгән атларны аякка бастырып булмады. Алар бер-бер артлы дөньядан китеп бардылар. Без, бүген җиңүгә өлеш керткәннәрне мактыйбыз, һәм дөрес эшлибез. Ә бит атлар кешеләрдән һич тә ким эшләмәделәр. Моны оныту — гаделлек түгел... Бервакыт үлгән атлар урынына авылга монгол атлары килә башлады. «Чыдамнар, ашауга та талымсызлар»,— дип мактадылар аларны. Мөгаен, дөресен әйткәннәрдер. Алар безнең атларга караганда кечкенәрәкләр, шулай да шактый җегәрлекләр иде. Әмма көн-төн эшләү, ашау начарлыгы бераздан аларны да юк итте...

Әйе, колхоз атына бервакытта да кадер булмады. Атны кем карый, ничек ашата, азыгын урламыймы, малларга ял бирәләрме-юкмы — мондый нәрсәләр вак-төяк булып тоелса да, хайваннар өчен хәлиткеч әһәмияткә ия. Авылда: «Әнә колхозның тагын бер аты үлгән»,— дип тыныч кына әйтүчеләр була. Ә үзеңнеке булдымы, бөтенләй башка хәл. Күптән түгел Сабит энемнән хат алдым. Ул узган елда колын сатып алуын, хәзер аның җигәрлек тайга әйләнеп баруын, яхшы ашаткач-карагач, тиз үсүен шатланып язган. Әлбәттә, ул үзе ашамаса да, иң элек атын кайгыртачак. Бу — кешенең табигатендә. Әле дә хәтерлим: эшкә җигәргә без бурлы бияне алырга тырыша идек. Чөнки, әткәйнең әйтүенә караганда, колхозга кадәр бурлы бия аларныкы булган. Ул бурлы бияне әле дә якын итә, кызгана иде. Без дә аткайның башыннан сыйпап ипи каптыра идек. Сугуфәлән кебек нәрсә бөтенләй юк. Менә шулай — үзеңнеке — якын.

Атның акыллы хайван булуына мин күптән ышандым. Колхозыбызның җирләре аркылысы да, буе да 6-7 километрга сузыла. Сугыш вакытында миңа җәй айларында көн дә бик күп җирләрне үлчәргә туры килде — кем күпме җир сөргән, тырмалаган, чәчкән, игеннәрне утаган, салам өйгән һ. б. Бу кадәр ялан-кырларны бер көндә җәяү йөреп чыгып булмый. Шуңа күрә атланып йөрергә дип миңа бер тай бирделәр. Бәхеткә, ул бик юаш, тыңлаулы булып чыкты. Мин җир үлчәгәндә ул әкрен генә юл буенда үлән утлый. Тышауламасам да ерак китми. Монда эшне бетергәч, башка урынга юл тота идек. Менә шуннан соң ярты гасырдан артык вакыт узган. Әмма ул тай тере булып һаман да күз алдында тора.

Билгеле булганча, халык язучысы Гомәр Бәширов Врангельны тар-мар итү сугышларында катнашкан, аннан соң хәрби хезмәтен көньяк Украина далаларында (Таврияда) дәвам иткән. «Миңа ат бирделәр. Ашау-эчү такы-токы, атларга азык та юк дәрәҗәсендә иде. Әмма мин, берничә иптәшем белән бергә тирә-юньнән атыма азык алып кайта идем. Ул шуны белә иде микән, миңа бик нык ияләште. Үзен чиста да тоттым. Ниһаять, хезмәт срогым тулды, кайтырга вакыт җитте. Минем өчен иң авыры — атым белән аерылышу булды. Мин аны бала сөйгән кебек маңгаеннан сыйпадым. Ә ул башын минем иңбашына салып, авыр сулады, күзләреннән яшь тамды»,— дип сөйләде аксакал язучыбыз яшьлеген искә алып.

Мин үзем атлар, гомумән, хайваннар дөньясына багышланган радио-телевидение тапшыруларын карарга, тыңларга, бигрәк тә атлар турындагы китапларны укырга яратам. Г. Ибраһимов, Л. Толстой, С. Аксаков әсәрләрен кат-кат укыйм. Г. Сабитовның Ерак Көнчыгыштан, армия хезмәтеннән качып, туган Минзәлә ягына кайтып җиткән ат турындагы хикәясе, А. Хәлимнең «Өч аяклы ат» повесте да укучыны дулкынландыра... Шулай да Дж. Олдридж (Англия) повесте хакында да сүз йөртмәкче булам. Аның кыскача эчтәлеге болай: инглиз галимнәре, каты табигать шартларына яраклашкан монгол аты белән инглиз атын кушып, яңа нәсел алмакчы булалар. Бер айгырны тотып, самолет белән Монголиядән Англиягә озаталар. Ерактан килгән кунакны зоопаркның киң вольерына урнаштыралар. Янына яшь бияләр кертәләр, әмма ул аларны кабул итми, тешли, тибә, куа. Шуннан соң пони «кызын» кертәләр. Монгол аты аны да бик кырыс кабул итә. Ләкин соңыннан ярата башлый. Бу хәл галимнәрне канәгатьләндерми. Алар бу икәүне этләргә консервалар ясау өчен французларга саталар. Малларны яр буенда баржадан бушатканда, җаен табып, болар качалар, һәм көньякка да, көнбатышка да түгел, көнчыгышка юл тоталар... Бик күп Европа илләрен үтәләр. Урыс җиренә кергәч, хәлләре җиңеләя төшә, юлларына азыклар да куялар. 15 мең километрлар җир үтеп, Монголиягә барып керәләр. Ат шатлыгыннан шул тирәне яңгыратып кешнәп җибәрә. Әмма тиздән аңа бик зур кайгы килә: колын тапканда пони үлә. Шулай да кечкенәсе исән кала. Понины күмәләр. Бераз үскәч, колынны Англиягә озаталар. Ә айгыр таулар арасына кереп югала. Кайчак аның моңсуланып, уйланып торуын күрәләр икән... Бу вакыйга хайваннарның акылы турында сөйләмимени?

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ.

ЙӨРӘГЕҢӘ КҮЧСЕН ЙОЛДЫЗЛАР МАТУРЛЫГЫ!

— Чын мәхәббәт бармы ул?

Шундый сорау белән еш язалар безгә хатларны «Сабантуй»ны укучы кыз һәм ир балалар. Менә шундый хаттан бер өзек. (Аны Пермь ягыннан Флорида исемле кыз язган.)

«Мин быел сигезенче классны тәмамладым. Мин авылның иң чибәр кызы. Алтынчы класстан бирле Альбертны яратам. Шушы хакта аңа биш хат та яздым. Ләкин ул бер хатыма да җавап бирмәде. Мине күрмәмешкә салышып йөри. Миңа ни эшләргә? Мәхәббәтемне ничек аңлатырга?»

Флорида сеңлем!

Ни дип җавап бирик без сиңа. Мәхәббәт — бөек, изге хис ул. Аны кешегә мәҗбүриләп тагып булмый. Матур яз айлары килгәндәй, күктә алтын йолдызлар кабынгандай, ул барыбер дә килмичә, йөрәкне яндырмыйча калмый. Бәлкем, вакытлар узу белән Альберт та сине аңлар. Йолдызларның матурлыгын күрер һәм сиңа карап сокланыр. Күңелендә җыр туар.

Менә шул уңай белән сиңа һәм синең яшьтәшләреңә шушы шигырь юлларын тәкъдим итәбез. Ул ялкынлы шигырь юлларын Казан кызы Гәүһәр Ибраһим-Хан иҗат иткән. Бу юлларда — яну, ялкын... Ул әнә шулай итеп күңелендәге дулкынлы хисләрен шигырь юлларына күчергән.

Әле алай гынамы — әлеге юлларда — мәхәббәт, чын сөю. Ул шигъри юллар (дөресен әйтим, тоташ бер китап) бер кешегә багышланган. Ул кеше татар һәм башкорт дөньясына киң билгеле. Сәхнә йолдызы. Шигырь дә аның исеме белән әйтелгән. Аңлаганнар аңлый.

Ә инде шигырь юллары авторына килгәндә, ул гап-гади татар кызы. Казан санаторийларының берсендә табибә булып эшли. Эшен бик ярата. Эшен яраткан кебек шигъриятне ярата. Гомумән, ул ярату хисләреннән генә тора кебек. Югыйсә, мондый илаһи сөю хисләрен яратмаган кеше яза алыр иде микән?

Гәүһәр ханымның яратуы бер яклы. Аның әлеге шигъри юлларын үзенә багышлаган кеше белми һәм уена да китергәне юк.

Кызыкмы бу? Юк, кызык түгел. Ярату хисе яраткан кешеңә барып ирешергә тиештер. Һәрхәлдә «Сабантуй» ирештерер аңа бу хисне.

Флорида сеңлем!

«Бармы ул чын мәхәббәт?»— дип сорыйсың син бездән. Бардыр. Бар. Югыйсә, Гәүһәр апаң кебек сылу кызлар уттан һәм ялкыннан гына торган мондый юлларны язмаслар иде.

Зур үс, Флорида сеңлем. Гомерең буе мәхәббәтле бул!

Госман САДӘ.



ХАТТАН ӨЗЕК

Яшел җәйнең июнь кичендә
Күрдем сине —
һаман исемдә.
Сәхнә тулы якты нурлар
иде —
Йөрәгемдә нурлар бүген дә.

Бер ялгызым...
Бүлмә буйлап йөрим
Татлы мәхәббәттән исереп,
Сәхнәдәге моңлы
җырларыңны
Күңелемнән тагын кичереп.

БУ ИРЕННӘР НИ ПЫШЫЛДЫЙ?

*«Ал мине,
ярат мине!
Мин дә йолдызлар тиңе!
Минем өчен генәдер
Ходай яраткан сине».*

* * *

*Бер үбәсем килә сине шашып,
Тыным кысылып,
Минем кебек әнә былбыл
сайрый,
Сине юксынып...*

*Иреннәрем янып көйсен иде
Шушы үбүдән...
Яңа җырлар туар... Ике йөрәк
Бергә тибүдән...*

МИН САГЫНАМ СИНЕ

Таңда кояш белән уянам,
Изге уйлар белән мин янам.

Җәй җылысын, ямен тоямын...
Синең янда һаман хыялым.

Колагымда чыңлый моңлы
җырларың.
Мин пышылдыйм: «Син бит —
минем Фиданым».

* * *

Үтә гомерләр... Һич тә
үкенмим,
Алда әле матур таңнарым.
Сызылган каштай таңнар
атканда
Яннарыңа оча җаннарым.

Гәүһәр ИБРАҺИМ-ХАН.



Баш мөхәррир өчен
Ләлә ГЫЙМАДИЕВА

Редколлегия: Роберт МИҢНУЛЛИН, Шәүкәт ГАЛИЕВ, Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ, Госман САДӘ, Илдар ЮЗЕЕВ.



«Сабантуй»ны оештыручылар — Татарстанның Мәгариф министрлыгы, Яшьләр оешмалары советы, Балалар фонды һәм редакциянең хезмәт коллективы. 1924—90 елларда «Яшь ленинчы» исеме белән чыкты.

Индекс—54124. Тираж—1 0000



Адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

Телефоннар:
49-36-86, 49-36-90,
49-36-77, 49-36-88,
49-36-94, 53-57-37.

Ярдәм итәргә теләсәгез:
р/счет 700161998/2345716
в Волжско-Камском акционерном банке РКЦ ГЦБ г. Казани МФО 265005 «Для фонда редакции».



Заказ 1845

Басарга кул куелды: 1995 ел, 31 июль, 15 сәгать.